| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**29.12.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 45** |

2021 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тәкъдим иткән 2021 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) карап, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы карар итте:

1. 2021 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның беркетелгән фараз планын (программасын) расларга.

2.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына 2021 елга Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программаларын) «Интернет» челтәрендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), сатулар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (http://www.torgi.gov.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы
Советы карарына
№ 45-ТРЗ, 2020 елның 29 декабре
кушымта

**2021 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. 2021 елга Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән.
2. 2021 елда Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру район милке структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, район бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән.
3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла.
4. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы) гамәлдә булганда, хосусыйлаштырыла торган мөлкәт исемлегенә Зеленодольск муниципаль районы Советы карарлары нигезендә үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

## II. 2021 елда хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

Хосусыйлаштыру планлаштырыла торган башка мөлкәт исемлеге

| № т/б | Исеме | Мөлкәтнең урнашу урыны | Хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 5 катлы кирпеч торак йортның янкорма кушып төзелгән торак булмаган подвал бинасы, файдалануга тапшыру (сатып алу) елы: 1972, мәйданы 147,6 кв. м. | Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Гоголь ур., 57 | 2021 елның II - III кварталы. |